**Казан шәһәре Думасының**
**2025 елның 14 маендагы 5-38 номерлы карары**

**Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә территориаль рекреация зонасы (Р2) (108 номерлы контур) һәм иҗтимагый-эшлекле билгеләнештәге объектларны урнаштыру зонасы (ОД) (41 номерлы контур) чикләрен үзгәртү өлешендә үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең 20 статьясынигезендә, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 30 гыйнварындагы 178 номерлы «Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә территориаль рекреация зонасы (Р2) (108 номерлы контур) һәм иҗтимагый-эшлекле билгеләнештәге объектларны урнаштыру зонасы (ОД) (41 номерлы контур) чикләрен үзгәртү өлешендә үзгәрешләр кертү турында Казан шәһәре Думасы карары проектын әзерләү хакында»гы карарын һәм 2025 елның 13 февраленнән алып 2025 елның 27 февраленә кадәр үткәрелгән иҗтимагый фикер алышулар нәтиҗәләрен исәпкә алып, Казан шәһәре Думасы **карар бирде:**

1. Казан шәһәре Думасының 2021 елның 16 августындагы 5-8 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә (алга таба – Кагыйдәләр) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. шәһәр төзелешен зоналаштыру (территориаль зоналар) картасында әлеге карарның 1 номерлы кушымтасы нигезендә, территориаль зона – иҗтимагый-эшлекле билгеләнештәге объектларны урнаштыру зонасы (ОД) (41 номерлы контур) чикләренә мәйданы 8459 кв.м булган 16:50:040101:693 номерлы җир кишәрлеген кертеп, территориаль зона – рекреация зонасы (Р2) (108 номерлы контур) чикләрен үзгәртергә.

1.2. әлеге карарның 1.1 пунктчасында күрсәтелгән территориаль зоналарның үзгәрә торган чикләрен Кагыйдәләр составында шәһәр төзелешен зоналаштыруның түбәндәге карталарында чагылдырырга:

- шәһәр төзелешен зоналаштыру (территориаль зоналар) картасында;

- территориаль зоналарның урам-юл челтәре, табигать-рекреация комплексы, махсус билгеләнештәге яшелләндерү, яр буе территорияләре ярдәмче зоналары күрсәтелгән шәһәр төзелешен зоналаштыру картасында;

- территориаль зоналарның территорияне югары интенсивлыкта файдалану, шәһәр төзелешендә әһәмияткә ия территорияләр ярдәмче зоналары күрсәтелгән шәһәр төзелешен зоналаштыру картасында;

- территориаль зоналарның ярдәмче зоналары: тарихи җирлек ярдәмче зонасы күрсәтелгән шәһәр төзелешен зоналаштыру картасында;

- чикләрендә территорияләрне комплекслы үстерүне гамәлгә ашыру күздә тотыла торган территорияләр картасында;

1.3. Кагыйдәләргә 1 номерлы кушымтаны әлеге карарга 2 номерлы кушымта (хезмәт урынында файдалану өчен) (китерелми) нигезендә территориаль зоналар чикләре урнашу урынының график тасвирламасы белән тулыландырырга;


1.4. Кагыйдәләргә 2 номерлы кушымтаны әлеге карарга 3 номерлы кушымта (хезмәт урынында файдалану өчен) (китерелми) нигезендә территориаль зоналар чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга.

**Шәһәр Мэры** **И.Р.Метшин**

Казан шәһәре Думасының
2025 елның 14 маендагы 5-38
номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре составында шәһәр төзелешен зоналаштыру (территориаль зоналар) картасы фрагменты**




**Шартлы билгеләр**

**ОД - 41**

Территориаль зона контурының тәртип номеры

Территориаль зона индексы

**Территориаль зона**

| **Төс** | **Индекс** | **Территориаль зона төренең атамасы** |
|---|---|---|
| | ОД | Иҗтимагый-эшлекле билгеләнештәге объектларны урнаштыру зонасы |
| | Р2 | Рекреация зонасы |
| | | Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре составында шәһәр төзелешен зоналаштыру (территориаль зоналар) картасы фрагменты чикләре |

**Башлыкның беренче урынбасары Д.Г.Калинкин**